СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 с. Сарманово № 111

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында гавами тыңлаулар тәртибе һәм уздыру турында нигезләмә хакында» 2007 елның 24 мартындагы 113 номерлы Совет карарына үзгәреш кертү турында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 1 статьясындагы 3 пунктының б пунктчасы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставы нигезендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында гавами тыңлаулар тәртибе һәм уздыру турында нигезләмә хакында» 2007 елның 24 мартындагы 113 номерлы Совет карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 14.2 пунктта «комиссия» сүзеннән соң «шундый фикер алышулар яисә тыңлаулар тәмамланган көннән алып унбиш эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М. Хөснуллин